Tukay, G. (2011). *Olugъ iubilei mənəsəbəte ilə khalyk өmidləre* [People's Expectations in Connection with the Great Jubilee ]. Gabdulla Tukay. Əsərlər: 6 tomda. Akademik basma. 2 tom: Шигъри әсәрләр (1909–1913). Tөz., tekst.,isk. həm aңl. əzerl. Z. R. Shaikheralislamov, G. G. Khusnutdinova, E. M. Galimzyanova, Z. Z. Ramiev. Pp. 282–282. Kazan', Tatar.kit.nəshr. (In Tatar)

Usmanov, M. (2014). *Istə kalgan iakty migellər* [Memorable Bright Moments]. Kazan utlary, No. 9, pp. 157–166. (In Tatar)

Zinnatullina, H. (1968). *Zrelost'* [Maturity]. Sovetskaia Bashkiria, fevral' 8. (In Russian)

# СҮЗ ОСТАСЫНЫҢ ИҖАТ ЛАБОРАТОРИЯСЕНӘ БЕР КАРАШ (НАҖАР НӘҖМИНЕҢ «ПАРИЖ ӨСТЕНДӘ» ШИГЫРЕ МИСАЛЫНДА)[1]

**Себастьян Цвиклински**,
Берлин Азат Университетының Османистика һәм тюркология институты,
Германия, 14195, Берлин ш., Фабекштр. ур. 23–25,
sebastian.cwiklinski@web.de.

Мәкалә Н. Нәҗминең 1985 елда язылган “Париж өстендә” шигыре мисалында шагыйрьнең иҗат лабораториясе мәсьәләләрен яктырта. Әдәби әсәрне комплекслы тикшерү методына таянып, әдипнең сүз остасы буларак индивидуаль иҗат итү стиле ачыклана, шигырьнең татар һәм башкорт телләрендәге вариантларына таянып, иҗат лабораториясенең үзенчәлеге, фикер үсеше, үзгәрешләрнең нигезе билгеләнә. Әлеге шигырь бу юнәлештә беренче тапкыр фәнни нигездә анализлана, шуңа бәйләп, шагыйрьнең эш стиле, язу үзенчәлеге, образлы фикерләү мөмкинлекләре, дөньяга карашы да төгәлләштереп барыла. Бу мәкаләнең фәнни яңалыгын һәм актуальлеген билгели. Тикшеренүнең төп максаты – “Париж өстендә” шигыренең татар һәм башкорт телләрендәге версияләрен чагыштыру нигезендә Н. Нәҗминең иҗат лабораториясе үзенчәлеген, индивидуаль иҗат итү стилен, дөньяга карашын ачыклау.

Әсәрнең ике телдәге вариантларын тикшерү аша, беренчедән, һәр әдәби текстның әдәби барышта үз урыны булуы, аның креатив иҗат процессында барлыкка килүе билгеләнә, Франция сәфәре сәхифәләре нигезендә «Париж өстендә» шигыренең иҗат ителү шартлары тәкъдим ителә. Икенчедән, Наҗар Нәҗми әсәре үрнәгендә әдәби текстларның төрле версияләренең фикри үзгәрешне, яңалыкны күрсәтүе ачыклана. Өченчедән, һәм башкорт, һәм татар әдәбиятына хезмәт иткән әдипнең татар һәм башкорт әдәбиятларына мөнәсәбәте дә билгеләнә.

**Төп төшенчәләр**: Н. Нәҗми, татар әдәбияты, башкорт әдәбияты, татар-башкорт әдәби бәйләнешләре.

## Кереш

Наҗар Нәҗми (1918–1999) – үз иҗаты белән татар һәм башкорт милли әдәбиятларын үстерүдә, аларны бөтен илгә танытуда зур роль уйнаган, ике арада әдәби күпер салган, мәдәниятара бәйләнешләрне баетуга лаеклы өлеш кerткән классик әдипләрнең берсе. Башкорт Википедиясендә ул Башкортстанның халык шагыйре, Салават Юлаев премиясе лауреаты (1972) булып тәкъдим ителә [Википедия, 2021]. Татар Википедиясендә исә танылган татар шагыйре буларак билгеләнә, рус телле энциклопедиядә татар һәм башкорт шагыйре булуы турында хәбәр ителә. Бәхәссез, Н. Нәҗминең поэтик таланты, шигъри фикере башкорт һәм татар сүз сәнгатьләренең көчле йогынтысын тоеп формалаша һәм үсә. Ул озак еллар дәвамында «Казан утлары» журналы редколлегиясе әгъзасы булып тора, татар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен Татарстанның Гаяз Исхакый исемендәге премиясенә лаек була. С. Сөләйманова, Р. Миңнуллин, Р. Гаташ, Г. Морат һ.б. әдипләргә дә йогынты ясый. Наҗар Нәҗми үзе бу хакта «Татар каны» җыентыгының кереш сүзендә болай дип билгеләп үтә: «Башкортостанның Дүртөйле районы Миңеште авылында туганмын. Бөтен шигырьләремне мин башкорт телендә язам, әмма ләкин татар темасы – татар халкының фаҗигале тарихы, аның язмышы – гомерем буе минем йөрәгемне тетрәтте һәм шуларга һичвакытта битараф кала алмадым; киләчәктә дә алар мине бик нык уйландырачак» [Нәҗми, 1997, б. 2].

Билгеле, безнең өчен кызыклы ягы һәм үзенчәлеге – Наҗар Нәҗминең һәр ике телдә дә актив иҗат иткән шагыйрь булуында. Аның башкортча шигырьләре 1938 елдан башлап дөнья күрә, татар телендәгеләре исә 1947 елдан иҗат ителә башлый. Әлеге мәкаләдә, бер шигырьнең төрле вариантларына таянып, әдипнең индивидуаль иҗат итү стилен, иҗат

[1] Автор проф. Д. Госмановага әтисе проф. М. Госмановның истәлекләрен файдалану мөмкинлеге тудырганы өчен рәхмәтен белдерә.

лабораториясен, фикер үсешен ачыклау күздә тотыла.

Наҗар Нәҗми иҗаты әдәби тәнкыйтьтә шактый бәяләнгән булып, өйрәнелү тарихы узган гасырның 50 елларына барып тоташа. Беренче фикерләр башкорт әдәби тәнкыйтендә Г. Әмири [Әмири, 1950], И. Абдуллин [Абдуллин, 1954], Э. Бикчәнтәев [Бикчәнтәев, 1951], М. Гафуров [Гафуров, 1954], М. Максимов [Максимов, 1955] һ.б. тарафыннан әйтелә. Алар әдипнең тәүге әсәрләренә төпле анализ ясый һәм әдәбиятка кайтаруга этәргеч бирә. 1960-70 елларда Н. Нәҗми иҗаты фәнни нигездә өйрәнелә башлый. Шагыйрьнең шигырь җыентыклары басылу да моңа этәргеч бирә, җыентыкларга атап язылган кереш мәкаләләрдә, вакытлы матбугат битләрендәге язмаларда Н. Нәҗми иҗатының төп үзенчәлекләре фәнни һәм тәнкыйди яссылыкта билгеләнә башлый. Г. Рамазанов [Рамазанов, 1954; Рамазанов, 1968], Х. Зиннәтуллина [Зиннатуллина, 1968], Р. Хәкимов [Хакимов, 1963], Г. Хөсәенов [Хөсәенов, 1961], К. Әхмәтйәнов [Әхмәтйәнов, 1977, б. 3-18], Ә. Хәбиров [Хабиров, 1969], В. Казыйханов [Казыйханов, 1993], Р. Әмиров [Амиров, 1988], С. Сафуанов [Сафуанов, 1998], Р. Бикбаев [Бикбаев, 1991] һ.б. хезмәтләрендә аның лирикасына хас үзенчәлекләр, поэтик осталыгы, образлы фикерләү хасияте билгеләнә: «иллюстративлыктан» китеп, лирик геройның эчке дөньясын сурәтләүгә йөз тотуы аша сүз сәнгатенә алып килгән яңалыклары, фәлсәфи лирика үсешенә керткән өлеше ачыклана. Мәсәлән, К. Әхмәтйәнов теоретик аспектта тикшерү нәтиҗәсендә шагыйрь әсәрләрендә «поэтик аймылыштыру» (поэтик туры килмәү), «поэтик полярлык», «ихласлык», «ситуативлык», «образлы берәгәйлек» (образлы бергәлек), «катлаулы гадилек» кебек күренешләрне аерып чыгара. Билгеле, шагыйрьнең поэтик стиле формалашуына йогынты ясаган алшартларны, аның әсәрләрендә күтәрелгән проблемаларны, лирик каһарман бирелешен анализлаган вакытта, субъектив фикерләр дә өстенлек ала. Н. Нәҗминең татар, башкорт әдәбиятында тоткан урыны, ике тугандаш әдәбиятның традицияләрен үстерүе һәм XX йөздә аларның эволюциясенә керткән өлеше анык бәя алмый кала [Хәйбрахманов, 2004, б. 9]. Әдип иҗатына төпле бәя Ә. Хәбиров тарафыннан бирелә. Галим Н. Нәҗминең поэтикасын өйрәнүгә зур өлеш кертә [Хәбиров, 1982, б. 31-33], аның лирикасында лирик герой концепциясенең бирелешен тирәнтен шәрехли [Хабиров, 1970; Хабиров, 1978;]. Әлеге эзләнүләр шагыйрьне башкорт әдәбияты классигы дәрәҗәсенә күтәрә, әдәби дөньясы үсеш-үзгәрештә анализлана, иҗаты башкорт әдәби процессы яссылыгында үз бәясен ала.

1970-80 елларда әдип иҗаты Л. Аннинский [Аннинский, 1970], В. Баранов [Баранов, 1963, б. 90-93], Я. Друц [Друц, 1970], И. Иванов [Иванов, 1963], И. Ростовцева [Ростовцева, 1976], И. Сотников [Сотников, 1966], А. Филиппов [Филиппов, 1968, б. 31-32] кебек рус тәнкыйтьчеләрендә кызыксыну уята. Аларның хезмәтләрендә исә интернациональлек алга чыга, Н. Нәҗми совет әдибе, «сугыш темасын тирән яктырта алган», «катлаулы һәм каршылыклы иҗтимагый-әхлакый якларны ачуга омтылышлы» шагыйрь буларак тикшерелә.

Шагыйрь иҗаты татар әдәби тәнкыйте игътибарыннан да читтә калмый. Бу юнәлештәге кызыклы фикерләр Р. Мостафин [Мустафин, 1970], С. Поварисов [Поварисов, 1978] һ.б. хезмәтләрендә урын ала. М. Ногман [Ногман, 1973], С. Хәким [Хәким, 1978, б. 3-5], Г. Хуҗиев [Хуҗиев, 1963], Г. Рәхим [Рәхим, 1988, б. 3-4], Р. Гаташ [Гаташ, 1993] кебек татар шагыйрьләренең публицистик, тәнкыйди язмаларында да шагыйрь иҗатына нәзари карашлар күзәтелә. Аның татар һәм башкорт әдәбиятын бәйләп торган үзәк булып, ике арада үзенчәлекле мәдәниятара диалог урнаштыра алуы ассызыклана, рухи мирасы татар әдәбияты классиклары фонында бәясен ала. Р. Хәйбрахманов эзләнүләрендә исә Н. Нәҗминең татар шигъриятендәге урыны шәхес һәм дәвер концепциясенә, стиль үзенчәлегенә таянып тикшерелә, аны үстерүгә керткән өлеше тәгаенләнә [Хәйбрахманов, 2004].

## Хезмәтнең методологик нигезе

Герменевтик эзләнүләр хезмәтнең методологик нигезе итеп алынды. Методик яктан Й. Нигъмәтуллина тәкъдим иткән «әдәби әсәрне комплекслы тикшерү» ысулы файдаланылды. Әдәби әсәрне комплекслы бәяләү барышында мөһим этапларның берсе төсендә галимә иҗади индивидуальлек мәсьәләсен аерып куя. Ул иҗади индивидуальлекне катлаулы, күпкатламлы бербөтен буларак карый һәм шушы системада дөньяны тою һәм дөньяны күзаллау, әдәби һәм образлы фикерләү тибы баскычларын, эстетик

идеалны, талантны аерып чыгара [Нигматуллина, 1976, с. 94-102]. Әлеге мәкаләдә шушы теоретик фикерләргә таянып, Н. Нәҗминең татар һәм башкорт версияләрендә дөнья күргән "Париж өстендә" шигырен тикшерү аша әдипнең индивидуаль иҗат итү стиле, иҗат лабораториясе тикшерелә.

**Фикер алышу**

1984 елның август ае. СССР Язучылар берлеге Франциягә оештырган туристик сәфәрдә илнең төрле якларыннан язучылар катнаша, алар арасында тарих фәннәре докторы, Казан университеты профессоры Миркасыйм Госманов (1934–2010), татар язучысы Ренат Суфиев (1939–2007), шагыйрь Нажар Нәҗми һәм аларның җәмәгатьләреннән торган кечкенә генә татар-башкорт төркеме дә була. Миркасыйм әфәнде билгеләп үткәнчә[2], сәфәр вакытында алар үзара бик дуслашып китә, галим белән Н. Нәҗми арасында гаять тыгыз аралашу башлана. Туристик группа белән бергә алар Эйфель манарасына, Монмартрга бара, бөтен Парижны гизеп чыга, кыска гына сәяхәт вакытында татар-башкорт мәсьәләсе турында гәпләшү форсатын да табалар, шигърият турында да фикер алышалар. Шушы сәфәр әлеге мәкаләне язуга этәргеч биргән шигырьгә иҗади җирлек тә була. Әсәрнең дөньяга килү факты ук кызыклы. Сәфәрнең соңгы көнендә туристик төркем Франция һәм Париж белән хушлаша, шушы хөрмәткә бер ресторанда оештырылган кичке аш вакытында Миркасыйм белән Нажар әфәнделәр ресторанның балконына чыгалар. Бу турыда соңрак киңкырлы татар галиме болай дип искә төшерә: «Балконга чыккач, рестораныбызның шактый биектә икәнлеге беленде. Меңләгән-мәңләгән ут белән яктыртылган төнге Париж шактый түбәндә иде. Беркадәре тын гына төнге Парижны күзәтеп торган Нажар агай: «Кабатла әле теге шигырьне»[3], – диде. Кабатладым:

Ат сәнең астыңдадыр, йөргел бу йирнең хәдден ал[4],

Нәгяһән[5] ул ат сәнең астыңда булгай – булмагай.

– Әйе, – диде ул, үзе белән сөйләшкән төсле, – форсатны кулдан ычкындырмаска кирәк шул. Тагын бу якларга килеп булырмы, юкмы... Ә мин башта икеләнеп кенә, теләр-теләмәс хәлдә юлга чыккан идем. Эш күп, дибез бит... Ә хәзер сәяхәтемнән бик тә канәгатьмен. Нинди гыйбрәтле дөньяны белмичә яшәгәнбез бит!... Дөрес әйткән шагыйрь: киләчәктә мондый форсат йә булыр, йә булмас... Бераз сүзсез тордык. Күңелсезрәк төс алган сөйләшүне икенчерәк якка борырга теләп: «Үзегезнең «Татар теле»[6]н укыгыз әле, Париж өстендә дә бер яңгырасын!» – дидем. Ул башта, хәтерләмим инде, дигән булды, аннары әкрен генә башлап, бер-ике строфасын узуга, кызып-кызып укыды.

Туган җирең Идел буе:
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле...

Гүяки бәйгегә кушылгач кызышып, авызлыгын чәйни-чәйни чапкан толпар ат төсле ярсыпярсып, тагын ике-өч шигырь укыды ул…» [Госманов, 2014, б. 163–164].

Әлеге сәфәрдән соң да ике дус арасында элемтәләр өзелми, сирәк кенә булса да, хатлар алышып торалар. 1985 елның сентябрь аенда М. Госмановка Н. Нәҗмидән чираттагы хат килеп ирешә, аның эчендә «Париж өстендә» дип исемләнеп, Миркасыйм әфәндегә аталган бер шигырь дә була. Шигырь беренче тапкыр 1987 елның 4 мартында «Кызыл таң» газетасында дөнья күрә [Нәжми, 2008, б. 56], шул ук елда «Казан утлары» журналында да нәшер ителә [Нәҗми, 1987]. Әмма бу вариантлар беренчел вариант булмый, шагыйрь аның беренче һәм икенче версияләрен мәсләктәше галимгә 1985 елның 12 һәм 16 сентябрь көннәрендә язган ике хатында җибәрә. Миркасыйм әфәнде болай дип искәртә: «Сентябрьдә җибәрелгән конвертында аның «Париж өстендә» дигән шигыренең машинкада басылган ике битле тексты килгән иде. Икенче битнең ахырында гына искәрмә рәвешендә

[2] М. Госмановның Н. Нәҗми турындагы истәлекләре беренче тапкыр 2014 елда "*Казан утлары»* журналында, ә 2019 елда кабат аның истәлекләр җыентыгында дөнья күрә. Галим истәлекләренең яңа басмасын әзерләгән проф. Д. Госманова белдергәнчә, 2014 елгы версия этисенеке була [Госманова, 2020].

[3] М. Госманов ресторанда татар-башкорт мәгърифәтчесе һәм шагыйре Шәмсетдин Зәкинең (1822–1865) бер шигырен укый.

[4] Хәдден алу — чигенә җитү [М. Госманов искәрмәсе].

[5] Нәгяһән — кинәттән, көтмәгәндә [М. Госманов искәрмәсе].

[6] Н. Нәҗминең «Татар теле» шигыре тәүге тапкыр 1968 елда "Казан утлары" журналында басыла. Мәкаләдә бу әсәрнең беренче строфасы китерелә.

түбәндәге сүзләр өстәлгән: Миркасыйм! Менә бер шигырь. Тел вә әдәбият кешеләре: «Бу кайсы берәүләргә ошамас», – диделәр. Әгәр дә сиңа ошаса – миңа шул җиткән [...] (*12.IX.85).*

Күп тә узмый, 16 сентябрьдә язылган өченче хаты да килде. Аны да тулысынча укып чыгыйк:

Миркасыйм!

«Париж өстендә» дигән шигырьнең бер юлын, сиңа җибәрер алдыннан, «Тел, лөгать вә... әхлак алмашузар»[7] дип төзәткән идем дә, уйлана торгач, үземә-үзем каршы килгәнемне аңладым. Бертуган халыкта нинди алмашулар булсын инде. Ул синең бәгыреңә кадалуы мөмкин. Шигырьнең шул урыннары шулайрак булды:

Язык түгел беркем алдында бу,
Туры килгәч язмыш язмышка.
Ә язмышлар, «тел, лөгать вә... әхлак»
Бер тамырдан, бер ук сулышта.
Без әле дә бер үк сулыштабыз –
Чит бер илдә – француз җирендә.
Ярсый-ярсый шигырь укышабыз
Йә татар, йә башкорт телендә.

Димәк, Нажар агай моннан дүрт-биш кенә көн элек җибәргән шигырьнең кайбер юлларын төзәтүне, дөресрәге, чынбарлыкка якынрак итеп әйтүне кирәк тапкан. Элек җибәрелгән беренче вариантта әлеге юллар болайрак яңгырый:

Язык түгел беркем алдында бу,
Туры килгәч язмыш язмышка.
«Тел, лөгать вә... әхлак алмашулар»
Алып барган алга, узмышка.
Без әле дә гүя узышабыз,
Чит бер илдә – француз җирендә,
Ярсып-ярсып шигырь укышабыз
Йә башкорт, йә татар телендә.

Үзгәртү, шулай итеп, принципиаль мәгънәгә ия иде. Күрәсең, Нажар агай элегрәк Парижда безнең арада булып алган шактый мәгънәле фикер алышуларны искә төшереп керткәндер бу төзәтүләрне» [Госманов, 2014, б. 164–165].

Шигырьнең үзгәртелү тарихы моның белән генә бетми. Ул 1988 һәм 1997 елларда, әле Нажар Нәҗми үзе исән вакытта, Казан һәм Уфада дөнья күргән татарча җыентыкларда кабат кечкенә генә, әмма мәгънәви үзгәрешләр кичереп, тагын ике тапкыр басыла. Иҗат лабораториясен тикшерү барышында бу яңа версияләр дә безнең өчен шактый кызыклы. «Париж өстендә» шигырендәге үзгәрешләрне әсәр мисалында төгәлләштерсәк, кызыклы картина туа. Татарча вариантларны чагыштыру барышында, без аның 1997 елгы версиясен нигез итеп алдык, чөнки ул – шагыйрьнең үзе әзерләгән соңгы версиясе. Моннан тыш безгә 1984 һәм 1985 елгы версияләрнең тулы вариантлары түгел, ә аерым кисәкләре генә мәгълүм. 1985 елның 12 сентябрендәге версияне «1985а», ә шул ук айның 16 сентябрь көнендәгесен «1985б» дип билгеләү кулай табылды. Шигырьнең строфаларга бүленеше, соңгы версиягә генә хас; 1987 елда басылган «Казан утлары» версиясендә соңгы дүрт юл гына аерым бер строфа буларак күрсәтелә, ә 1988 елдагысында строфага бүленеш бөтенләй юк.

**Париж өстендә**

*Казан дәүләт университеты профессоры*
*Миркасыйм Госмановка*

Без Эйфельдә... Уч төбендә кебек
Бөтен Париж – Җир һәм Ил[8] даны.
Әнә Бастилия... Монмартр... Конкорд...
Ә янында[9] Марс яланы.

Париж – тарих... Күпме күкрәү үткән,
Күпме исем монда яшьнәгән.
(Парижны да күрми торып, димен,
Моңа кадәр[10] ничек яшәлгән?)

Без биектә... Без – башкорт
һәм татар,
Без зур милләт Париж өчен дә.
– Сөйлә әле[11], – дидең, – «Татар теле»н,
Яңгырасын Париж өстендә[12].

Без татар һәм башкорт –
кан кардәшләр,
Миндә исә тибә ике кан:
Үзем башкорт, әмма татар теле –
Анам теле миңа тумыштан[13].

Язык түгел беркем алдында бу,
Туры килгәч язмыш язмышка[14].
Ә язмышлар «тел, лөгать вә... әхлак»[15]

[7] Бу форма имля хатасы түгел, «алмашулар» сүзенең башкорт теленнән алынмасы, чөнки сүзнең башкортчасы «алмашауҙар» була.

[8] Нәҗми, 1987: ил
[9] Нәҗми, 1987: эргәдә - Нәҗми, 1988: якында
[10] Нәҗми, 1987: тиклем
[11] Нәҗми, 1988: Сөйлә әле,
[12] Нәҗми, 1987: Яңгырасын Париж өстендә...
[13] Нәҗми, 1987: Үзем башкорт, әмма туган телем Татарлашып килгән тумыштан.
[14] Нәҗми, 1987: язмышка;

Бер тамырдан, бер ук сулышта[16].

Без әле дә бер үк сулыштабыз[17][18]
Чит бер илдә – француз җирендә,
Ярсып-ярсып[19] шигырь укышабыз
Йә башкорт, йә татар телендә[20].

Аста Париж... Син уйларың белән
Алып киттең мине Казанга.
Париж түбәсеннән киттең алып,
Бүгенгедән үткән заманга.

Кайдан карарга соң зур Казанның
Ак бүгенен, кара үткәнен –
Сөембикә манарасыннанмы,
Манарасыннанмы әллә
Баумандагы кызыл чиркәүнең?

Юк, карыйк яңа биеклектән[21] –
Син укыткан биек бинадан.
О, университет! Альма-матер,
Күпләр мәшһүр аңа бинаән!

Күз алдында менә
Сөембикә[22],
Тукай, Җәлил, Ирек мәйданы[23],
Әнә Болак, Идел, Яңа бистә,
Арча кыры, Печән базары...[24]

Казанда да күпме күкрәү үткән,
Күпме исем балкып яшьнәгән!
Бер уйласаң, Парижны да күрми,
Яшәп булган... ә бит яшәлгән![25]

Без Әйфельдә[26] – аста кайный
Париж –
Исемендә дөнья тарихы.
Бу мәл Казан ничек кайный икән?[27]

Казан, Казан – татар Парижы!..

Билгеле, шигырьләрне редакцияләү барышында аерым үзгәрешләрнең керүе табигый, алар еш кына, иҗтимагый мәгънәгә ия булмыйча, тел-стильне камилләштерү максатыннан башкарыла. Әмма аерым үзгәрешләр иҗтимагый-мәдәни яңгырашка ия була. Бу очракта, безнең карашыбызча, икенчесе өстенлек ала. Н. Нәҗми шигыренең беренче татарча версиясендәге башкортча сүзләрне 1988 һәм 1997 елларда дөнья күргән версияләрдә аңлы төстә татарча сүзләр белән алмаштыра. Мәсәлән, «Ә эргәдә Марс яланы» юлындагы «эргәдә» сүзе 1988 елдагы версиядә «якында», 1997 елда исә «янында» сүзләре белән алмаштырыла. «Моңа тиклем ничек яшәлгән?» юлы, соңгы версияләрдә «Моңа кадәр ничек яшәлгән?» дип үзгәртелә.

М. Госманов үзе болай дип аңлата: «Нажар Нәҗми аңлатуынча, шигырьне җибәрер алдыннан, аның «Тел, лөгать вә... әхлак алмашулар» юлын, «Тел, лөгать вә... әхлак» белән алмаштырып бертуган халыкта алмашуларның бар булуының мөмкин булмаганы һәм татар дусының йөрәгенең кадалуын теләмәгәне белән нигезли. [Госманов, 2014, б. 164]. «Алмашулар» сүзенең аның фикеренчә ни өчен кадаулы булуы мөмкин булачагын аңлар өчен, бу юлның тарихына карарга кирәк. Бу юл – Нажар Нәҗминеке түгел, ә Габдулла Тукайның «Олугъ юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре» шигыреннән өземтә» [Госманов, 2014, б. 164]. Тукай бу шигырьне 1913 елда Романовлар династиясенең Россиядә патшалык итә башлавының 300 еллыгына багышлап иҗат итә. Безне кызыксындырган юлның оригиналы менә болай:

Рус җирендә без әсәрле, эзле без,
Тарихында бер дә тапсыз көзге без.
Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып [Тукай, 2011, б. 384].

Өзектән күренгәнчә, Н. Нәҗми интертекстуальлек алымына мөрәҗәгать итеп, Тукайның «Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» юлын үз шигырендә «Тел, лөгать вә... әхлак» дип үзгәртә, ягъни, «алмашу»ны гына түгел, «гадәт» сүзен дә төшереп калдыра. Кызык, шагыйрь «гадәт»не ни өчен төшереп калдырды икән? Тукай шигыренең язылу контекстын искә алганда, Н. Нәҗми тарафыннан «гадәт» сүзенең төшереп калдырылу сәбәбе аңлашыла: Г. Тукай, «Олугъ юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре» шигырендә рус халкын татар

---

[15] Нәҗми, 1987: Ә язмышлар, «тел, лөгать вә әхлак»
[16] Нәҗми, 1987: сулыштан.
[17] Нәҗми, 1987: сулыштабыз,
[18] Нәҗми, 1985а: «Тел, лөгать вә... әхлак алмашулар»
[19] Нәҗми, 1985б: Ярсый-ярсый - Нәҗми, 1985а һәм Нәҗми, 1987: Ярсып-ярсып,
[20] Нәҗми, 1987 һәм Нәҗми, 1988: Я башкорт, я татар телендә.
[21] Нәҗми, 1987: Юк, карыйк без яңа биеклектән
[22] Нәҗми, 1987: Күз алдына минә Сөембикә,
[23] Нәҗми, 1987: Тукай, Җәлил, «Ирек мәйданы»,
[24] Нәҗми. 1987: Арча кыры, «Пәчән базары».
[25] Нәҗми, 1988дә бу юлдан соң яңа строфа башланмый.
[26] Нәҗми, 1987: Без — Әйфельдә
[27] Нәҗми, 1987 һәм Нәҗми, 1988: кайный икән?..

халкының «абые» буларак тасвирлый. Әмма шул ук вакытта әдәби телгә сизгер булган Тукай телләр үсеше процессын тоемлап, кардәш һәм кардәш булмаган телләрнең үзара бәйләнешен, бер-берсенә уңай йогынтысын да шигъри калыпка салган. Бәлки, Н. Нәҗми, татар һәм башкортлар очрагында шундый абый-эне мөнәсәбәтләрен күрмәве сәбәпле, бу юлны үзгәрткәндер.

«Париж өстендә» шигыренең төрле версияләрендә Н. Нәҗми үз туган теленә һәм татар теленә карашын да үзгәртә: шигырьнең һәр өч версиясендә милләт ягыннан үзен башкорт буларак тасвирласа да, туган тел мәсьәләсендә үзгәреш күренә: беренче версиядә үз туган телен «татарлашып килгән тумыштан» буларак сурәтли, соңгы версияләрдә исә шагыйрь татар телен «анам теле» дип билгели. Шәрехләүгә бу аспекттан якын килгәндә, үзен башкорт дип исәпләгән Н. Нәҗми «материаль якынлык, материаль охшашлык» зур булган башкорт һәм татар телләренең мөстәкыйльлеген көчәйтергә дә омтыла. Шулай итеп, үзгәрешләр поэтик яссылыкта гына калмыйча, әдипнең дөньяга карашы үзгәрешен дә ассызыклый.

Тагын бер кызыклы фактка игътибар юнәлтү мөһим. 1985 елның 29 апрелендә М. Госмановка юллаган хатында Наҗар Нәҗми Франциягә сәяхәте турында шигырьләр язу белән шөгыльләнүен искәртеп китә [Госманов, 2014, б. 164]. Шундый шигырьләр «Француз дәфтәреннән» исеме белән 1987 елның 1 февралендә башкортча «Совет Башҡортостаны» газетасында басыла [Нәжми, 2008, б. 33]. Франция сәяхәтенә багышланган сигез шигырь арасында «Париж өҫтөндә» дип аталган шигырь дә бар, ягъни шигырь иң башта татарча язылган булса да, беренче тапкыр башкорт версиясендә дөнья күрә [Нәжми, 2012, б. 47–48].

Шигырьнең башкорт белән татар телләрендәге версияләрен үзара чагыштырганда, «Казан утлары» журналындагы татарча вариантның башкорт телендәге вариантына иң якын версия булуы күзәтелә. «Казан утлары» версиясендә кебек үк Н. Нәҗми анда да туган телен «татарлашып килгән тумыштан» дип бирә, башкорт телендә киң кулланылышта булган «эргә» һәм «тиклем» сүзләре дә урын ала. Шунысы кызык: 1985 елның һәр ике версиясендә булган башкортча «йә... йә» сүзләрен («Йә башкорт, йә татар телендә») 1987 һәм 1988 елларның версияләрдә «Я... я» дип алмаштырган, 1997 елда исә бу сүзләр кабат элекке рәвешенә, башкортча формага әйләнеп кайта. Моннан тыш, башкортча һәм татарча версияләр арасында күзгә ташланган тагын бер аерма бар: шигырьнең соңгы өлешендә Казан тасвирында шәһәрнең иң мөһим, символик мәгънәгә ия урыннары санала. Башкорт версиясендә Сөембикә (манарасы) урынына татарча вариантларда булмаган Кабан күле телгә алына. Гомумән алганда, Сөембикә (манарасы) башкорт әдипләре тарафыннан һич тә начар кабул ителми. Мәсәлән, шагыйрь Кадим Аралбай «Ҡазан дәфтәренән» шигырь тупланмасында Сөембикә манарасына аерым бер шигырь багышлап, аны Көнчыгыш халыкларын уятучы һәм татар белән башкортларны берләштергән бер символ итеп күтәрә [Аралбай, 2011].

Гомумән алганда, Н. Нәҗминең «Париж өстендә» шигыренең язылу тарихы кызыклы нәтиҗәләргә алып килә: беренчедән, ул һәр әдәби текстның үз тарихы булуын, аның креатив төстә иҗат процессында барлыкка килүен күрсәтә, М. Госманов шәрехләгән Франция сәфәре детальләре укучыга «Париж өстендә» шигырен язу фикеренең нинди әдәби-мәдәни һәм рухи шартларда тууын аңлата. Икенчедән, шагыйрь иҗат лабораториясендә әдәби текстларның төрле вариантларда яшәве, бу версияләрнең һәрберсенең әсәр турында мөһим фактларны җиткерүе раслана. Өченчедән, «Париж өстендә» әсәре башкорт һәм татар әдәбиятларына хезмәт иткән әдипнең дөньяга карашын, әдәби процесстагы урынын да ачыкларга ярдәм итә, шагыйрь үзен ике әдәбият арасында түгел, ә мөстәкыйль әдәбиятлар буларак кабул иткән татар һәм башкорт әдәбиятлары вәкиле итеп күрә. Аның иҗаты ачыктан-ачык башкорт һәм татар әдәбияты дип икегә бүленә: Н. Нәҗми башкортча язган бер шигырен дә татарчага һәм, киресенчә, татарча язган бер әсәрен дә башкортчага тәрҗемә итми. «Париж өстендә» шигыре исә бу яктан да үзенчәлекле әсәр булып тора.

**Әдәбият**

*Абдуллин И.* «Саҡырылмаған ҡунаҡ» пьесаһы һәм спектакле тураһында // Ҡыҙыл Башҡортостан. 1954. 4 апрель.

*Амиров Р.* «Вся жизнь от радости до ран...» // Вечерняя Уфа. 1988. 5 февраля.

*Аннинский Л.* Мой дом и мой мир // Литературная газета. 1970. 1 июля.

*Аралбай Ҡ.* Сөйөмбикә манараһы // Һайланма әҫәрҙәр. 2 том: поэмалар, шиғырҙар. Өфө: Китап, 2011. Б. 461–462.

*Әмири Г. [F?].* Шиғырҙың тыуыуы // Ҡыҙыл Башҡортостан. 1950. 29 октябрь.

*Әхмәтйәнов К.* Ғүмер буйы асыла барған сер // Нәжми Н. Әҫәрҙәр, өс томда. Т. 1. Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1977. Б. 3-18.

*Баранов В.* Шрам войны // Урал. 1963. № 9. С. 90-93.

*Бикбаев Р.* Эволюция современной башкирской поэзии. М.: Наука, 1991. 140 с.

*Бикчәнтәев Ә.* «Яҙғы йыр» // Ҡыҙыл Башҡортостан. 1951. 29 апрель.

*Гаташ Р.* Мин бер якты югарылык күрәм... // Шәһри Казан. 1993. 27 февраль.

*Гафуров М.* О стихах Назара Наджми // Ленинец (Уфа). 1954. 23 ноября.

*Госманов М.* Истә калган якты мизгелләр // Казан утлары. 2014. № 9. Б. 157–166.

*Друц Я.* Поэт живет дважды // Литературная Россия. 1970. 2 октября.

*Зиннатуллина Х.* Зрелость // Советская Башкирия. 1968. 8 февраля.

*Иванов И.* Взято из жизни // Советская Башкирия. 1963. 7 апреля.

*Казыйханов В.* Пусть будут разные песни // Вечерняя Уфа. 1993. 2 февраля.

*Максимов М.* Стихи ровестника // Литературная газета. 1955. 26 мая.

*Мустафин Р.* Осенние тропы // Вечерняя Уфа. 1970. 23 ноября.

*Нәҗми Н.* Париж өстендә // Казан утлары. 1987. № 6. Б. 83–84.

*Нәҗми Н.* Париж өстендә // Нәҗми Н. Сиңа барам: Шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. Б. 28–29.

*Нәҗми Н.* Татар каны: Шигырьләр һәм поэмалар. Уфа: Мәгърифәт, 1997. 105 б.

*Нәжми Н.* 2008. Биобиблиографик күрһәткес [төҙ. М.Х. Баһуманова, Ә. И. Әхмәтйәнова]. Өфө: Милли китапхана, 2008.

*Нәжми Н.* Фанцуз дәфтәренән: Жермон армияһы. Фонтен де Ваклюзе. Һау бул, Марсель! Нотр-Дамда орган концерты. Париж, 25 август, Сталинград майҙаны. Париж өҫтөндә. Хәтер. Урамдарҙа. // Һайланма әҫәрҙәр. 2 том. Өфө: Китап, 2012. Б. 42–49.

*Нигматуллина Ю.Г.* Методология комплексного изучения художественного произведения. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1976. 108 с.

*Ногман М.* Канатлы җырлар // Социалистик Татарстан. 1973. 21 июнь.

*Поварисов С.* Хисләргә бай иҗат // Кызыл таң. 1978. 5 февраль.

*Рамазанов Г.* Лирика любви и дружбы // Советская Башкирия. 1954.25 ноября.

*Рамазанов Г.* Поэзия высокого накала // Советская Башкирия. 1968. 8 февраля.

*Рәхим Г.* Моңнар шагыйре // Нәҗми Н. Сиңа барам. Казан: Татар.кит.нәшр., 1988.Б. 3-4.

*Ростовцева И.* С миром большим один на один ... // Литературная газета. 1976. 28 января.

*Сафуанов С.* «Я всю жизнь стучусь в ворота человеческих сердец...» // Известия Башкирии. 1998. 5 февраля.

*Сотников И.* Звезды поэта // Ленинец (Уфа). 1966. 17 ноября.

*Тукай Г.* Олугъ юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре // Габдулла Тукай. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 2 том: Шигъри әсәрләр (1909–1913) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З. Р. Шәйхелисламов, Г. Г. Хөснетдинова, Э. М. Галимҗанова, З. З. Рәмиев. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 384.

*Филиппов А.* И лирика, и гражданственность // Агидель. 1968. № 2. С. 31-32.

*Хабиров А.* Поэтический голос Наджми // Советская Башкирия. 1969. 26 марта.

*Хабиров А.* Зеркало души поэта // Наш современник. 1970. № 7.

*Хабиров А.* К новым высотам. // Литературная Россия. 1978. 17 февраля.

*Хабиров А.* Зов любви и памяти // Советская Башкирия. 1982. 6 октября.

*Хакимов Р.* Жизнелюбие // Ленинец (Уфа). 1963. 15 февраля.

*Хәйбрахманов Р.* Нажар Нәҗми шигърияте: стиль, дәвер һәм шәхес концепциясе. Казан, 2004. 160 б.

*Хәким С.* Бәхетле шагыйрьләр // Нәҗми Н. Ут күрше. Казан: Татар.кит.нәшр., 1978. Б. 3-5.

*Хөсәенов Г.* Шиғри тамсылар // Совет Башҡортостаны. 1961. 27 май.

*Хуҗиев Г.* Сөю сүзләре // Социалистик Татарстан. 1963. 14 июль.

Назар Наджми // https://ru.wikipedia.org/wiki/%D0%9D%D0%B0%D0%B7%D0%B0%D1%80_%D0%9D%D0%B0%D0%B4%D0%B6%D0%BC%D0%B8 (мөрәҗәгать итү вакыты: 02.08.2021).

Нажар Нәҗми // https://tt.wikipedia.org/wiki/%D0%9D%D0%B0%D2%97%D0%B0%D1%80_%D0%9D%D3%99%D2%97%D0%BC%D0%B8 (мөрәҗәгать итү вакыты: 02.08.2021).

Назар Нәзми // https://ba.wikipedia.org/wiki/%D0%9D%D0%B0%D0%B7%D0%B0%D1%80_%D0%9D%D3%99%D0%B6%D0%BC%D0%B8 (мөрәҗәгать итү вакыты: 02.08.2021).

# СОПРИКОСНОВЕНИЕ С ТВОРЧЕСКОЙ ЛАБОРАТОРИЕЙ ПИСАТЕЛЯ (НА ПРИМЕРЕ СТИХОТВОРЕНИЯ НАЗАРА НАДЖМИ «НАД ПАРИЖЕМ»)[1]

**Себастьян Цвиклински**,
Институт Османистики и тюркологии Свободного университета Берлина,
Германия, 10117, г. Берлин, ул. Фабекштр. д. 23–25,
sebastian.cwiklinski@web.de.

В статье изучаются особенности творческой лаборатории Н. Наджми на примере анализа стихотворения «Над Парижем», написанном в 1985 г. Особенности индивидуального стиля писателя изучаются с помощью метода комплексного анализа текста. Своеобразие творческой лаборатории писателя раскрывается через сопоставление татарского и башкирского вариантов одного стихотворения, позволяющее выявить эволюцию авторского замысла, внутренние предпосылки вносимых изменений. Указанное стихотворение анализируется в таком ракурсе впервые, что позволяет расширить представление о стиле работы автора, особенностях его индивидуальной манеры письма, образного мышления, мировоззрения. В этом и состоит новизна данной научной работы.

Сопоставительный анализ текстов на татарском и башкирском языках, с одной стороны, позволяет нам познакомиться с предысторией создания стихотворения «Над Парижем», родившегося на основе впечатлений от поездки во Францию, в Париж, определить его место в творчестве писателя. С другой стороны, на основе анализа разных версий текста мы можем увидеть, в каком направлении развивается творческая мысль автора. В третьих, выявляется индивидуальное отношение писателя к башкирской и татарской литературе, работавшего во славу двух братских литератур.

**Ключевые слова**: Н. Наджми, татарская литература, башкирская литература, татарско-башкирские литературные взаимосвязи.

[1]Автор благодарит профессора Д. Усманову за предоставленную возможность использования воспоминаний отца профессора М. Усманова.